**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 3 июнь № 401

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 нче пунктта:

егерме икенче абзацтагы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе тарафыннан» сүзләрен «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 нче пунктта:

3.3.1 нче пунктчада:

текстка түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә күзәтчелек чараларын гамәлгә ашыру кысаларында, әйләнә-тирә мохит объектларының һәм әйләнә тирәгә пычратучы матдәләрне чыгару һәм ташлау чыганакларының пробаларын сайлап алу, тикшерү (сынау), үлчәүне үткәрә;»;

сигезенче – унсигезенче абзацларны тугызынчы – унтугызынчы абзацлар дип санарга;

3.3.2 нче пунктчада:

текстка түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче абзац өстәргә:

«әйләнә-тирә мохит объектларының пробаларын, автоматлаштырылган стационар һәм күчмә экология постларын кулланып, шулай ук лаборатория ысуллары белән сайлап алу, тикшерү (сынау), үлчәүне үткәрә;»;

бишенче һәм алтынчы абзацларны алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга;

3.3.6 нче пунктчада:

текстка түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«төбәк дәрәҗәсендәге объектларның дәүләт экология экспертизасы өлкәсендә эшләр оештыруны регламентлаштыра торган норматив хокукый актларны кабул итә;»;

икенче – унберенче абзацларны өченче – уникенче абзацлар дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\401.doc